Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге
Белкино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

15 октябрь, 2024 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлегенең Белкино торак пунктында 2024 елның 15 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 148 (йөз кырык сигез).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 80 (сиксән).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 80 (сиксән).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә түбәндәге сорау буенча **гражданнар җыены карары**: «Сез 2025 елда Белкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (зиратка юл)» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Белкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Белкино авыл җирлеге башлыгы А.Н. Меньшов